**СОВЕТ МАКАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422602 с.Ташкирмень,
ул. Мира, д.40
тел: 8-(84378) -4-85-25
факс: 8-(84378) -4-85-25
e-mail: Makar.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАКАРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422602 Ташкирмән авылы,
Тынычлык урамы, 40 нчы йорт
тел: 8-(84378) -4-85-25
факс: 8-(84378) -4-85-25
e-mail: Makar.La@tatar.ru

**2023елның 23 октябре** **169 номер**

# КАРАР

**«Лаеш муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2011 елның 21 декабрендәге 41 номерлы Макаровка авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

"Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" Федераль законга һәм "Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында" 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Макаровка авыл җирлеге Советы **карар чыгарды**:

1. «Лаеш муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2011 елның 21 декабрендәге 41 номерлы Макаровка авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуныүз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Макаровка**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **В.В.Кормачев**

*Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы*
*Макаровка авыл җирлеге Советының*
*2023 елның 23 октябрендәге 69 номерлы*
*карарына кушымта*

**«Лаеш муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2011 елның 21 декабрендәге 41номерлы Макаровка авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

1) **12 статьяның 10 пунктында**

- "Интернет" челтәрендә" сүзләрен "рәсми сайтларда" сүзләренә алмаштырырга;

2) **15 статьяның 1 абзацы**

- «һәм җирле үзидарә органнары» сүзләрен «җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга, «хезмәткәрләр,»сүзеннән соң «ведомство буйсынуындагы оешмалар хезмәткәрләре» сүзләренә алмаштырырга;

3) **1 пунктның 7 статьясында**

- «һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләрен өстәргә .